КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 июль г.Казань № 555

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1101 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 2 июль, 455 нче; 2016 ел, 3 октябрь, 701 нче; 2016 ел, 22 декабрь, 968 нче; 2017 ел, 13 ноябрь, 866 нчы; 2018 ел, 20 февраль, 102 нче; 2019 ел, 25 февраль, 125 нче; 2019 ел, 5 сентябрь, 775 нче; 2020 ел, 2 апрель, 250 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан

социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле VI бүлек өстәргә:

«VI. 2020 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектында катнашучы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлекләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе

6.1. Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге

6.1.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлекләрендә (алга таба – көндезге бүлекләр) ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтүдән файдалануга урнашканда социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар өчен социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә тапшырылырга тиешле документлар:

| Т/с | Тапшырыла торган документлар исемлеге | Документ бирүне гамәлгә ашыручы оешма | Документның гамәлдә булу вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы | социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән |
| 2. | Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының шәхесен таныклый документ | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 3. | Законлы вәкилнең шәхесен, статусын һәм вәкаләтләрен таныклый торган документлар* | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, опека һәм попечительлек органнары | законнар нигезендә |
| 4. | Инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасы** | федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре | инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасында күрсәтелгән |
| 5. | Яшәү урыны буенча йогышлы авыруларның | медицина оешмалары | 3 көн |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | булмавы турында белешмә кәгазе | | |
| 6. | Гражданның яшәү урыны буенча аның белән бергә теркәлгән затлар турында мәгълүматлар бирелгән документ | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | 30 көн |
| 7. | Яшәү урыны буенча граждан белән бергә яшәүче затларны аның гаилә әгъзаларына кертүнең хокукый нигезләрен раслый торган документларның күчермәләре | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, граждан хәле актларын теркәү органнары | законнар нигезендә |
| 8. | Гражданның, аның гаилә әгъзаларының акчалата рәвештә алынган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәтләрне бушлай күрсәтү өчен җан башына уртача керемне билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 18 октябрендәге 1075 номерлы карары нигезендә аның җан башына уртача керемен билгеләгәндә исәпкә алына торган һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләп чыгару өчен файдаланыла торган, соңгы 12 айда алынган керемнәре булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) | керемнәр булу (булмау) турында документлар (мәгълүматлар) бирүгә вәкаләтле органнар (оешмалар) | законнар нигезендә |

*Эшкә сәләтсез яки эшкә чикләнгән дәрәҗәдә сәләтле дип билгеләнгән тәртиптә танылган затка хезмәт күрсәтү өчен урнашканда бирелә.

**Инвалидларга хезмәт күрсәтү өчен урнашканда бирелә.

## 6.2. Социаль хезмәтләрне бушлай йә түләүле яки өлешчә түләүле күрсәтү кагыйдәләре

6.2.1. Көндезге бүлекләрдәге өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр түләүсез яки түләүле йә өлешчә түләүле (гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турындагы федераль законнар нигезендә һәм бу Тәртипнең I бүлегендәге 1.5 бүлекчәсе нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә торган күләмдә) күрсәтелә.

## 6.3. Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче эшчәнлегенә карата таләпләр

6.3.1. Көндезге бүлекләрдә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү граждан яки аның законлы вәкиле һәм социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итүче арасында төзелә торган социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамә нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә биргән көннән бер тәүлек эчендә гамәлгә ашырыла.

Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамәнең мөһим шартлары булып социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасында билгеләнгән нигезләмәләр, шулай ук алар түләүле яки өлешчә түләүле күрсәтелгән очракта, социаль хезмәтләр күрсәтү кыйммәте тора.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тиешле тәэмин итүченең социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалануга соравы аларны күрсәтү мөмкинлегеннән артып киткән очракта, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы билгеләгән тәртиптә формалаштырыла торган чират нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.3.2. Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү һәм социаль хезмәт күрсәтүдән төшерү социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының һәрберсенә шәхси эш булдырыла, анда социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле документларның күчермәләре, социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамә теркәлә.

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның шәхси эшләрен, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар урнашу һәм чыгу журналларын исәпкә алуны һәм саклауны законнар нигезендә гамәлгә ашыра.

6.3.3. Көндезге бүлекләрдә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү өчен социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүченең социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның көндезге мәшгульлеген һәм буш вакытын оештыру өчен социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның, шул исәптән терәк-хәрәкәт аппаратында төрле бозылышлары

булганнарның ихтыяҗларын исәпкә алып җиһазландырылган бүлмәләре булырга тиеш.

Көндезге бүлекләрдә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр түбәндәге бинада (биналарда) яки урыннарда күрсәтелергә тиеш:

инвалидлар өчен алардан файдалану мөмкинлеге турындагы законнарның таләпләренә, санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә, хезмәтне саклауның һәм янгын куркынычсызлыгының норматив таләпләренә җавап биргән;

коммуналь-көнкүреш хезмәте күрсәтү чаралары һәм телефон элемтәсе белән тәэмин ителгән;

стандартлар, техник шартлар, башка норматив документлар таләпләренә җавап бирә торган һәм күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең тиешле сыйфатын тәэмин итә торган махсус һәм табель җиһазлары, аппаратура һәм приборлар белән җиһазландырылган.

6.3.4. Социаль хезмәтләрне тулы һәм сыйфатлы итеп күрсәтү өчен кирәкле махсус техник җиһазландыру составына социаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле җиһазлар, приборлар, аппаратура, техник чаралар һәм инвентарь керә, шул исәптән:

социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар белән дәресләр үткәрү өчен җиһазлар һәм дидактик материаллар;

альтернатив һәм өстәмә коммуникация чаралары (пиктограммалар, схемалар, күрсәткечләр һ.б.);

буш вакытны оештыру өчен җиһазлар һәм уеннар җыелмалары комплектлары, телевизорлар, музыкаль уйнаткычлар һ.б.

## 6.4. Социаль хезмәт күрсәтүләр стандарты

6.4.1. 2020 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектында катнашучы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлекләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүләрнең исемнәре, тасвирламасы һәм аларны күрсәтү күләмнәре, социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү күрсәткечләре бу Тәртипнең 5 нче кушымтасында китерелгән.

6.4.2. Көндезге бүлекләрдә ярымстационар формада социаль хезмәтләр түбәндәгеләргә күрсәтелә:

«Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткән, хәтере белән, йә башка когнитив бозылышлар белән бәйле проблемалары булган гражданнарга;

интеллект бозылышлары, аутистик спектрдагы тайпылышлары булган 18 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге инвалидларга.

6.4.3. Көндезге бүлекләрдә ярымстационар формада социаль хезмәт күрсәтү вакыты социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасы нигезендә социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы шартнамә белән билгеләнә.

Көндезге бүлекләрдә социаль хезмәтләр эш көннәрендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан расланган график нигезендә күрсәтелә. Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыга социаль хезмәт күрсәтү көннәренең бер атнага саны социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы (аның законлы вәкиле) белән килештереп билгеләнә.

Социаль хезмәтләр көндезге вакытта көненә дүрт сәгатькә кадәр гомуми дәвамлылык белән күрсәтелә.

6.4.4. Көндезге бүлекләрдә, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның яшен, когнитив бозылышларын, психологик туры килүен исәпкә алып, саны 10 кешегә кадәр булган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар төркемнәре булдырыла.

6.4.5. Социаль хезмәт күрсәтү кысаларында социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның көндезге мәшгульлеге һәм буш вакыты оештырыла.

6.4.6. Көндезге бүлекләрдә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүләрне финанслауның җан башына нормативы ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

6.4.7. Көндезге бүлекләрдә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәткәндә түбәндәгеләр тәэмин ителергә тиеш:

социаль хезмәт күрсәтү оешмасы территориясе буенча хәрәкәт иткәндә, шулай ук хезмәт күрсәтүләрдән файдаланганда социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларга булышлык күрсәтү мөмкинлеге;

социаль хезмәт күрсәтү оешмасы территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, оешмага керү, аннан чыгу һәм аның эчендә хәрәкәт итү өчен (шул исәптән кресло-колясқаларда хәрәкәт итү өчен), утырган хәлдә ял итү өчен мөмкинлек, шулай ук җиһазларны һәм мәгълүмат бирә торган җайланмаларны уңайлы итеп урнаштыру;

текст белдерүләрен тавыш белдерүләре белән кабатлап әйтү, социаль хезмәт күрсәтү оешмасын Брайльнең рельефлы-ноктaлы шрифты ярдәмендә эшләнгән билгеләр белән җиһазландыру, аларның ярдәме белән оешма территориясендә язулар, билгеләр һәм башка текст һәм график мәгълүмат белән таныштыру, шулай ук тифлосурдотәрҗемәчегә, озата баручы этләрләргә керергә рөхсәт бирү;

тавыш белән бирелә торган мәгълүматны текстлы мәгълүмат, язулар һәм (яки) яктылык сигналлары белән кабатлау, рус ишарә телен (сурдотәрҗемәне) кулланып, күрсәтелә торган социаль хезмәтләр турында мәгълүмат бирү, сурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт бирү.»;

әлеге Тәртипкә 5 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасында социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә
5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 6 июль, 555 нче
карары редакциясендә)

2020 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектында катнашучы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлекләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәт күрсәтүләрнең исемнәре, тасвирламасы һәм аларны күрсәтү күләмнәре

| Т/с | Социаль хезмәт күрсәтү исеме | Социаль хезмәт күрсәтү тасвирламасы | Социаль хезмәт күрсәтү күләме (максималь саны) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | үлчәү берәмлеге | максималь саны, күрсәтү дәвамлылыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Социаль-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 1.1. | Социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү | Бер социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыга социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мәйданнар бирү | кв.метр | Социаль хезмәт күрсәтү чорында 18 кв.метр |
| 1.2. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нормативлар нигезендә йомшак инвентарь һәм санитар-гигиена билгеләнешендәге товарлар белән тәэмин итү | Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыны санитар-гигиена билгеләнешендәге товарлар (кәгазь сөлге, бәдрәф кәгазе, сабын) белән тәэмин итү | данә (комплект) | социаль хезмәт күрсәтү чорында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган нормативлар нигезендә |
| 2. | Социаль-медицина хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 2.1. | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрү | Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы белән сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру һәм төрле авыруларны профилактикалау, акыл һәм физик эшкә | чаралар | социаль хезмәт күрсәтү чорында атнага бер тапкыр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | сәләтне арттыруны мотивацияләү мәсьәләләре буенча санитар-аң-белем бирү эше | | |
| | | | | |
| 2.2. | Социаль-медицина мәсьәләләре буенча консультация бирү | Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыга сәламәтлекне тәэмин итү һәм саклау, авыруларны профилактикалау, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру мәсьәләләре буенча консультация бирү;<br>яшькә бәйле адаптацияләү үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирү;<br>тормыш сыйфатын яхшыртуга ярдәм итә торган тернәкләндерү һәм карау чаралары турында мәгълүмат бирү | хезмәт күрсәтүләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында айга 1 тапкыр |
| 2.3. | Сәламәтләндерү чараларын үткәрү | Хезмәт күрсәтү сәламәтләндерү характерындагы физик күнегүләр комплексын (зарядка) үткәрүне күздә тота | чаралар | социаль хезмәт күрсәтү чорында көнгә 1 тапкыр |
| 3. | Социаль-психологик хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 3.1. | Социаль-психологик консультация бирү | Социаль хезмәт күрсәтү составына түбәндәгеләр керә: социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының психик халәтен бәяләү, аның психологик проблемаларын ачыклау, социаль хезмәт күрсәтүне оештыру шартларында күз алдында тотыла торган ярдәм күрсәтүнең күләмен һәм төрләрен билгеләү, психологик мәсьәләләрне, шәхесара бағланышлар мәсьәләләрен хәл итүдә квалификацияле ярдәм күрсәтү, шулай ук әлеге проблемаларны кисәтү максатларында профилактик әңгәмәләр үткәрү | чаралар | урнашканда 1 тапкыр, социаль хезмәт күрсәтү чорында айга 2 тапкыр |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Социаль-педагогик хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 4.1. | Социаль-педагогик коррекция (диагностика һәм консультация бирүне кертеп) | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучының социаль дезадаптацияләү диагностикасын үткәрүне, тормыш эшчәнлегенең өлкәләрен компенсацияләү яки торгызу шартларын билгеләүне;<br>коррекцион чаралар (педагогик ысуллар белән хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучы шәхесенең үзенчәлекләрен һәм сыйфатларын үзгәртүгә, шәхеснең тулы кыйммәтле үсешен һәм эшчәнлеген тәэмин итү максаты белән ярдәм күрсәтүгә, сөйләмне, хәтерне саклауга, торгызуга һәм үстерүгә юнәлдерелгән әңгәмәләр, тренинглар, дәресләр) үткәрүне | чаралар<br>чаралар | урнашканда 1 тапкыр, социаль хезмәт күрсәтү чорында кварталга 1 тапкыр<br>социаль хезмәт күрсәтү чорында көнгә 1 тапкыр |
| 4.2. | Уңай мәнфәгатьләр формалаштыру | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота:<br>социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар белән социомәдәни эшчәнлек, иҗат, кул эшләре һ.б. ысуллары ярдәмендә рекреацион чаралар оештыруны һәм үткәрүне;<br>социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларга социомәдәни тернәкләндерү, физик культура һәм спорт чаралары буенча тернәкләндерү мәсьәләләре буенча мәгълүмат һәм консультация бирүне | чаралар<br>чаралар | социаль хезмәт күрсәтү чорында көнгә 1 тапкыр<br>социаль хезмәт күрсәтү чорында айга 1 тапкыр |
| 4.3. | Буш вакытны оештыру | Хезмәт күрсәтү түбәндәгеләрне күздә тота: | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче оешмасы чикләрендә социомәдәни чаралар оештыруны (теле-тапшырулар һәм нәфис фильмнар карау, китаплар уку, өстәл уеннары оештыру һ. б.); | чаралар | социаль хезмәт күрсәтү чорында көнгә 1 тапкыр |
| | | социаль хезмәт күрсәтү-ләрдән файдаланучылар бе-лән бәйрәмнәр, экскурсия-ләр оештыруны һәм үткә-рүне, концертларга баруны һ.б., иҗат коллективлары чакыруны | чаралар | социаль хезмәт күрсәтү чорында 2 атнага 1 тапкыр |
| 5. | Социаль-хокукый хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 5.1. | Юридик хезмәт күрсәтүләрдән фай-даланууда ярдәм күрсәтү | Социаль хезмәт күрсәтү-ләрдән файдаланучыга га-мәлдәге законнар нигезендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтү хокукына ия гражданнар категорияләре турында мәгълүмат бирү. Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүдән файдалану хокукына ия булган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларга мондый ярдәм күрсәтү очракларын һәм тәртибен аңлату, шулай ук аларны күрсәтүдән файдалануга ярдәм күрсәтү. Социаль хезмәт күрсәтүләр-дән файдаланучыга (аның законлы вәкиленә) социаль хезмәт күрсәтүләрдән фай-даланучының социаль хезмәт күрсәтүгә, шулай ук социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә хокукы белән бәйле мәсьәләләр буенча консультация (консульта-ция) оештыру | консуль-тацияләр | социаль хезмәт күрсәтү чорында кирәк булуга карап |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 6. | Хезмәт эшчәнлегендә чикләүләре булган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларында хезмәтләр күрсәтү | | | |
| 6.1. | Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль-тернәкләндерү чаралары үткәрү | Хезмәт күрсәтү аралашу, шәхесара мөнәсәбәтләрне булдыру осталыгы, үз-үзен контрольдә тоту, шәхси сакланган булу күнекмәләрен саклап калуга, формалаштыруга һәм үстерүгә, социаль һәм көнкүреш эшчәнлегенең элементар гомумкабул ителгән нормаларын һәм кагыйдәләрен үзләштерүгә юнәлдерелгән дәресләр үткәрүне күздә тота.<br>Торак киңлеген (фатирны, йортны) куркынычсыз оештыру принциплары турында мәгълүмат бирү | чаралар | социаль хезмәт күрсәтү чорында көн саен |

2020 – 2022 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру буенча пилот проектында катнашучы халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләренең, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләренең көндезге бүлекләрендә өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар формасында социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфаты һәм аның нәтиҗәләрен бәяләү күрсәткечләре

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Исәпләп чыгару формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның иң чик күрсәткече | Индикаторның авырлык коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | Хисап чорында тикшерү үткәргәндә ачыкланган санитария законнарын бозулар саны | процент | $\frac{Кн}{Кп} \times 100$,<br>монда:<br>Кн – контроль-күзәтчелек органнарын тикшерү актларында күрсәтелгән бозулар саны; | тикшерү акты | 0 | 8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Кп – контроль-күзәтчелек органнарын тикшерүләр саны | | | |
| 2. | Оешмада социаль хезмәт күрсәтүдә булган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның гомуми санынnан социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар саны | процент | $\frac{ПСУ}{ОПС} \times 100$, монда: ПСУ – социаль хезмәт күрсәтү оешмасында социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар саны; ОПС – социаль хезмәтләр күрсәтү белән социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчегә мөрәҗәгать иткән социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның гомуми саны | мониторинг системасы | 100 | 5 |
| 3. | Социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның күрсәтелгән социаль хезмәтләрдән канәгать булуы | процент | сораштыру нәтиҗәләре буенча социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның канәгатьлелеге буенча билгеләнә: $\frac{О_к + О_д}{2 \times О} \times 100 = У$, монда: $О_к$ – сораштырылган һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатыннан канәгать булган социаль хезмәт күрсәтүләрдән | социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны сораштырулар нәтиҗәләре буенча | 80 | 4 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | файдаланучылар саны; $О_к$ – сораштырылган һәм хезмәт күрсәтүләр уңайлыгыннан канәгать булган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар (яки аларның законлы вәкилләре) саны; О – сораштырылган социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның (яки аларның законлы вәкилләренең) гомуми саны | | | |
| 4. | Оешмаларның социаль хезмәтләр күрсәтүче белгечләр белән комплектланган булуы | процент | $\frac{УС}{ЧСШ} \times 100$, монда: УС – социаль хезмәт күрсәтү оешмасында эшләүче белгечләр саны; ЧСШ – штат расписаниесе буенча белгечләр ставкалары саны | мониторинг системасы | 100 | 4 |
| 5. | Оешмада социаль хезмәтләр күрсәтүдән файдалану мөмкинлеге | процент | түбәндәгеләр буенча билгеләнә: сайтта һәм мәгълүмати стендларда социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре, социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүче мони- | тикшерү нәтиҗәләре буенча, мониторинг системасы | 80 булу (20%) | 5, шул исәптән: 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | торлары турында актуаль мәгълүмат булу; | | | |
| | | | социаль хезмәтләр күрсәтелә торган объектлар (бина-лар, урыннар) ур-нашкан террито-рия буенча мөстә-кыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге булу; | | булу (20%) | 1 |
| | | | социаль хезмәтләр күрсәтелә торган бинага (урыннар-га), шул исәптән кресло-коляска белән тоткарлык-сыз керү һәм аннан чыгу мөмкинлеге булу; | | булу (20%) | 1 |
| | | | күрү һәм мөстә-кыйль хәрәкәт итү функциясендә тотрыклы бозы-лышлары булган инвалидларны озатып йөрү, шу-лай ук инвалид-ларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүгә кома-чаулый торган киртәләрне узуда ярдәм күрсәтү өчен җаваплы хезмәткәрләр булу; | | булу (20%) | 1 |
| | | | социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар-ның тормыш эшчәнлегендәге чикләүләрне | | булу (20%) | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | исәпкә алып, мәгълүмат бирү җайланмаларын урнаштыру | | | |
| 6. | Социаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын яхшырту һәм аларны күрсәтү нәтиҗәлелеген арттыру | процент | социаль хезмәт күрсәткәндә оешма эшчәнлеген камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралардан чыгып билгеләнә: | мониторинг системасы | 70 | 8, шул исәптән: |
| | | | грант алуга конкурста катнашу (ел саен); | мониторинг системасы | булу (10%) | 1 |
| | | | грант алу конкурсында җиңү (ел саен); | мониторинг системасы | булу (10%) | 1 |
| | | | социаль хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре; | сыйфатка бәйсез бәяләү үткәрүнең эксперт бәясе | кимендә 85 балл (15%) | 1 |
| | | | ачыкланган бозуларны бетерү; | мониторинг системасы | булу (10%) | 1 |
| | | | социаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатының раслaнган эчке системасы булу; | мониторинг системасы | булу (15%) | 1 |
| | | | социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә ведомство яки дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында ачыкланган хокук бозулар булмау; | тикшерү үткәрү турында акт | булу (15%) | 1 |
| | | | яңа технологияләр, эш формаларын һәм ысулларын кертү; | мониторинг системасы | елга кимендә 1 (10%) | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | социаль хезмәтләр күрсәтүче хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү планын үтәү | мониторинг системасы | булу (15%) | 1 |